Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районын Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының беренче утырышы

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

21 сентябрь, 2020 ел № 5

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы, Ленино-Кокушкино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының айлык акчалата түләү күләмен арттыру турында» карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы, Ленино-Кокушкино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре өчен түләү турында» 2018 елның 27 апрелендәге 56 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге советы карарына (2019 елның 30 гыйнварындагы 87 номерлы карар белән расланган үзгәрешләр белән) үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы айлык акчалата хезмәт хакының күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә 2020 елның 1 октябреннән арттырырга. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладлары күләмен 1,03 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р.Сәйфетдинов